КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 декабрь г.Казань № 1329

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 15 июль, 684 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 15 июль, 684 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

1 пунктка «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Бюстлар урнаштыру һәм янәшәдәге территорияне төзекләндерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

исемендә «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

1 пунктка «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

5 пунктта:

«а» пунктчасында «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

«б» пунктчасында «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

6 пунктта:

өченче абзацта «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

дүртенче абзацта «бюстлар» сүзеннән соң «, стеллалар» сүзен өстәргә;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. i муниципаль берәмлек ($C_{i}$) бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_i = P_1 + P_2 + P_3,$$

монда:

$P_1$ – Россия Федерациясе территориясендә сынлы сәнгать әсәрләрен иҗат итү кыйммәтен билгеләү методикасы һәм расланган федераль төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә билгеләнә торган бюстларны урнаштыру (аларны иҗат итүне кертеп) чыгымнары;

$P_2$ – Россия Федерациясе территориясендә сынлы сәнгать әсәрләрен иҗат итү кыйммәтен билгеләү методикасы һәм расланган федераль төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә билгеләнә торган стеллаларны урнаштыру (аларны иҗат итүне кертеп) чыгымнары;

$P_3$ – расланган федераль төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә билгеләнә торган янәшәдәге территорияне төзекләндерү чыгымнары.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Башка бюджетара трансфертларны файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече түбәндәге күрсәткечләрнең берсе:

урнаштырылган бюстлар саны (кимендә 1 берәмлек);

урнаштырылган стелалар саны (кимендә 1 берәмлек).

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән һәм фактта ирешелгән башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин